ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2020 ел Баулы шәһәре №16

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районында мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган кайбер административ регламентларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр тезелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Аквакультура (балыкчылык) һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 27 декабрендәге 502-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына 7нче кушымта), түбәндәге өстәмәне кертергә:

Административ регламентка 1нче кушымтада 29) пунктчадан соң түбәндәге эчтәлектәге 29.1) пунктны өстәргә:

«29.1.) күрсәтелгән максатларда, дәүләт яки муниципаль милектә булган балыкчылык кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе нигезендә (алга таба-балыкчылык кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе) товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыручы затка җир участогы.

2. Җир участогын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану теренә рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ

регламентына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына 34нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» бүлегендә:

3.5.1. пунктының беренче абзацында «ун көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

И.И. Гозәеров